**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 август № 586

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил хезмәткәрләрен файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү методикасын раслау турында

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил хезмәткәрләрен файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәрү буенча эшне камилләштерү максатларында һәм «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның $18^1$ статьясындагы 2 пункт нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә чит ил хезмәткәрләрен файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү методикасын (алга таба – Методика) расларга.
2. Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә, Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Методика нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә чит ил хезмәткәрләрен файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнашырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\586.docx